СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

13 ноябрь, 1998 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 129 (8286) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ӘШЕ БАРНЫҢ АШЫ БАР

***Быел да Уңыш бәйрәме үткәреп була икән! Басу-кырларыбыз көткәннән күпкә тыйнаграк уңыш бирсә дә, икътисадый кризис дигән нәрсә бугаздан ныграк ала барса да, теләгән хуҗа хезмәт алдынгыларының күңелен күрү, аларның хезмәтенә нәтиҗә ясау җаен таба ала икән. "Өмет" агрофирмасы 6 ноябрь көнне үткәргән Уңыш бәйрәме шундый якты, җылы бәйрәм булды.***

Егоркино Мәдәният йортында уздырылган бәйрәмгә агрофирмага кергән һәр кооператив үзенең иң лаеклы, эшчән механизаторларын, шоферларын вәкил итеп юллаган иде. Агрофирманың яшәү тарихы зур булмаса да, телгә алырдай уңышлары, зурларлык алдынгылары шактый икән. Алар хакында агрофирма рәисе И.Н. Мөхәммәтов сөйләде. Иң әүвәл, агрофирма бөртекләрнең гектарыннан уртача район күрсәткеченнән югары уңыш алды. Ильяс Нургалиевич кыр эшләренә кыскача анализны ике-Кузнецов исемендәге һәм Мичурин исемендәге кооперативлар җирлегендә ясады. Беренчесендә уртача уңыш 13,3 центнер булса, мичуринлылар аны 15,6 центнер алганнар. Кузнецовлылар сабан бодаеннан 20шәр центнер уңыш җыеп, тулаем агрофирманы бодай белән тәэмин иткәннәр. Ә менә чөгендер мичуринлыларда мулрак уңыш биргән: гектардан 106 центнер. Сүз дә юк, болар ниятләгән саннардан күпкә кайтыш, әмма бит аны субъектив сәбәпләр нәтиҗәсе диеп булмый. Шуңа хуҗалык рәисе быелгы елда да зур фидакарьлек белән хезмәт куйган алдынгыларны хөрмәт белән телгә алды һәм сәхнәгә чакырды. Бөртекле культуралар суктыруда иң әйбәт нәтиҗәләргә ирешкән С.Николаев, И.Николаев, А.Имуков, игеннәрне теземнәргә салучы А.Ефимов, Г.Васильев, И.Ермуллин, ашлык ташучы шоферлар А. Андриянов, Р.Нуриев, туңга сөрү алдынгылары В.Тимофеев, Григорьян Вартан, туфрак әзерләүдә әйбәт эшләгән П.Петров, азык әзерләүче В.Осипов, уҗым чәчүдә алдынгы булган П.Семенов, француз комбайнында чөгендер игүче В.Фролов һ.б., һ.б. - һәммәсенә зур бүләкләр тапшырылды, җылы теләкләр юлланды.





*Рәсемнәрдә: хуҗалыкның алдынгы механизаторлары Станислав Николаев һәм Владимир Тимофеев. Н. АЗИЗОВ фотолары.*

Булдыклы хуҗалыкта бер бәйрәм дә эш, киләчәк турында сөйләшүдән башка узмый. И.Н.Мөхәммәтов та зур хуҗалыкның ниятләре, киләчәккә планнары белән теләп бүлеште. Узган ел сабагы аларны бераз тактиканы үзгәртергә мәҗбүр иткән. Быел, мәсәлән, минераль ашламаны чама белән генә кулланырга ниятлиләр, аның кирәкле күләменең 80 проценты туплап та куелган инде.

(Ахыры 4нче биттә).

# Республика сулышы

* Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, РФ татарларының Милли - мәдәни мөхтәрияте Федераль Советы рәисе Индус Таһиров РФ Хөкүмәте Рәисе Евгений Примаков, Дәүләт Думасы Рәисе Геннадий Селезнев һәм милли сәясәт министры Рамазан Абдулатыйпов исеменә мөрәҗәгать хаты юллады. Анда Россия төбәкләрендә нәшер ителүче татар басмалары хакында БТКның борчылуы чагыла.

Анда билгеләп үтелгәнчә, бүгенге заманда, килеп туган финанс кытлыгы сәбәпле, мәгълүмат чараларына ябылу куркынычы яный Бу бигрәк тә милли басмаларга кагыла. БТК Башкарма комитеты рәисе Россия төбәкләрендәге татар милли матбугатына федераль службаларның һәм җирле хакимиятнең ярдәм күрсәтүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Аерым алганда, 1998 елның дүртенче кварталына һәм 1999 елгы бюджетта бу басмаларга федераль һәм төбәк бюджетларыннан дотацияләр бүлеп бирүне карауны үтенә.

* Россия Федерациясенең "Хәтер китабы" Халхин Гол һәм Хәсән күле яны сугышларында һәлак булган совет сугышчыларының исемлеген бастырып чыгарды. Хәсән күле янында гына да 960 кызыларммияче ятып калган. Шуның 17се - Татарстаннан.

* Моннан өч ел элек кенә чыга башласа да, "Гаилә календаре"н күпләр яратып та өлгерде. Әле шушы көннәрдә генә аның яңасы - 1999 ел өчен чыгарылганы үз укучыларына барып иреште. Аны Ранис Газизов төзегән.

**("Татар -Информ").**

# ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

"Лениногорск тампонаж эшләре идарәсе" чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятенең Нурлат филиалы башлыгы **Тәнзил Кәбир улы МУСИНга** ТР Президенты Указы белән "Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе" дигән мактаулы исем бирелде.

***

"Татнефтепром" ачык акционерлык җәмгыятенең Зүзәй нефть промыселы башлыгы урынбасары **Валерий Алексеевич НИКОЛАЕВ** ТР Президенты Указы нигезендә Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛДЫГЫЗМЫ ӘЛЕ?

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

*Терлекчелектә - кыш*

# ИҢ МӨҺИМЕ - ТӘРТИП

Терлекчелектә гаять җаваплы чор җитте - малларны ничек тә исән - сау кышлатып чыгару бурычы тора. Быел азык запасы былтыргыдан күпкә чигенке булуын исәпкә алганда, бүген чыннан да иң элек малларның баш санын саклап калу, продуктлылыкны ничек тә тотрыклы тоту турында кайгыртырга туры килә. Ә бу бары тик һәр фермада үрнәк тәртип булдырганда гына мөмкин. Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең терлекчелек бүлеге белгечләре - бүлек башлыгы Р. Сиражетдинов һәм баш зоотехник Х. Фәтхуллин белән бергәләп ике - РСУ һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларында терлекчелекнең торышы белән танышканда иң элек шул мәсьәләгә игътибар иттек, урыннарда белгечләрнең дә игътибарын нәкъ шуңа юнәлтергә туры килде, чөнки ике хуҗалыкның да фермаларында күп кенә уңай яклар булса да, кул җитмәгән, күз уңыннан читтә калган нәрсәләр дә шактый иде.

РСУ ярдәмче хуҗалыгы - мөгезле эре терлекләрнең баш санын узган елгы дәрәҗәдә саклап кала алган берничә хуҗалык арасында һәм моның чыннан да шулай икәнлегенә хуҗалыкның ике фермасында да үз күзең белән ышанасың. Күршеләре - "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында бүген мал абзарларының я өлешчә, я бөтенләй буш булуыннан аптырасалар (анысы бер бүген генә килеп туган хәл түгел һәм моның сәбәпләре бик күп), Тимерлектә исә мөгезле эрек терлекләргә урын чак - чак кына җитә. Сүз беренче чиратта үстерү һәм симертүдәге маллар турында бара. Димәк, шулкадәр малны тиешенчә карап, тамагын тук тоткан тәкъдирдә хуҗалыкның икътисадый хәле тотрыклы буласына ышаныч зур. Тиешле тәртип булдырылганда, әлбәттә. Тик, кызганычка каршы, әлегә анысы җитеп бетми әле. Дөрес, ике бүлекчәдә дә былтыр үстерү һәм симертүдәге малларны бәйләмичә асрауга күчерүне бик оешкан төстә хәл иттеләр һәм ул алым быел да кулланылышта. Рационга килгәндә, концентрат азык былтыргы кебек иркен булмаса да, сусыл азыкларга кытлык кичермиләр, печәннең төрлесен мул итеп әзерләп куйганнар, саламнары да җитәрлек. Дөрес, көзге пычрак печән һәм саламны җитәрлек кайтарырга мөмкинлек бирмәгән әле, әмма җир катырып, юллар төшкәч, ул мәсьәлә уңай хәл ителер, салам кардаларга кибәне белән кертеп куелыр дип ышанабыз. Ә менә сенаж - силос салыр өчен кардаларда утлыклар я бөтенләй юк, я маллар санына карата җитәрлек түгел. Ә инде мал азыгының пычракта аяк астына салынганы мал авызына кереп бетмәгәнлеге көн кебек. Красная Майна бүлекчәсендә үстерү һәм симертүдәге малларның рационы да бик такыр әле - ә булган азыкны да шулай кысып тотуның файдасыннан бигрәк зыяны күбрәк булачак бит - терлекләрне симертү вакыты да бик озакка сузылачак, таналарның каплатылыр чакка тиешле авырлыкка җитмәү куркынычы да бар. Ә анысының нәтиҗәсе нинди буласын терлекчелектән хәбәрдар кеше яхшы аңлый. Һәм былтырлы - быеллы бозау алуда шактый гына яхшы күрсәткечләргә ирешкән тимерлекләрнең кабат чигенеш ясаулары да бик мөмкин. Дөрес, ике фермада да бозаулату бүлекләре эшли, ташлаткан сыерларны аерымрак рацион белән ашату оештырылган, бары тик соңгыларына соны парлап бирүне генә җайга саласы бар. Яшь бозауларны салкында асрау ысулын кертеп тә шактый оттылар алар һәм анысыннан быел да баш тартмаганнар. Тик яхшы тәҗрибәнең җиренә җиткереп алып барылуы турында гына кайгыртырга кирәк. Анысы салкында асрала торган бозаулар бүлегендә аслыкларны коры тотуга ирешүгә кагыла.

Болардан тыш та фермаларда шактый гына җитешсезлекләр бар әле. Аларның барысы хакында да, әйткәнебезчә, урындагы белгечләргә, урта буын җитәкчеләргә җиткерелде, алар үзләре дә кимчелекләрнең булуы белән килештеләр һәм аларны тиз арада бетерергә тырышачакларын әйттеләр һәм шуңа күрә аларның барысы хакында да ваклап язып торуны урынсыз дип саныйбыз. Алда әйтелгәннәрен исә башка күп хуҗалыкларга да кагылганга күрә генә санап киттек. Шунысы да бар, терлекчелектәге җитешсезлекләр бу тармакка җитәкчелек тарафыннан игътибарның җитәрлек булмавы аркасында да. Бу турыда сүз аерым.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

# ХОКУКЫЙ ДӘҮЛӘТ ТӨЗҮ

## Ф.Х.МӨХӘММӘТШИН,

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**



***1992*** **елның 6 ноябрендә республика Югары Советы суверен Татарстанның Конституциясен кабул итте. Ул онытылмас көннән соң алты ел вакыт үтте.**

Тарихи вакыт тиз үтүчән. Конституция проектын бөтенхалык тикшерүе, аның гомуми концепциясе турындагы кайнар дискуссияләр һәм бәхәсләр, кертелгән төзәтмәләр буенча килештерү комиссиясенең күп хезмәт куйган эшчәнлеге, халыкара хокукый экспертизалар һ.б. бик күп нәрсәләр өр-яңа тарих фактларына әверелде. Бүген Татарстан Республикасының Төп Законы Татарстан дәүләтчелегенең аерылгысыз атрибуты һәм аның барлык гражданнары тормышының сәяси-хокукый нормасы булып тора.

Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү элекке СССРдагы сәяси һәм икътисадый процессларның үсеш логикасы белән алдан билгеләнде. Аның нигезен тәшкил итүче маддәләрдә дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең төп идеяләре һәм принциплары - 1992 елның 21 мартында республиканың дәүләт статусын күтәрү турындагы референдумда якланган идеяләр һәм принциплар юридик яктан беркетелде. Элекке автономия анда яшәүче күп милләтле халыкның ихтыярын һәм мәнфәгатьләрен чагылдыручы суверен демократик дәүләт, хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара вәкаләтләр бүлешү турындагы Шартнамә нигезендә Россия Федерациясе белән ассоциацияләнгән халыкара хокук субъекты дип игълан ителде. Тора-бара исә дәүләтара мөнәсәбәтләрнең бу яңа тибын булдыруның сәяси-хокукый формуласы Татарстанның кыю һәм новаторлык адымы буларак халыкара күләмдә танылды.

Бүген без, нәкъ менә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасындагы Шартнамә Россиянең демократик юлдан үсешенә куәтле импульс бирде, дип горурлык белән әйтә алабыз. Аңа кул кую нәтиҗәсендә халыкларның үзбилгеләнү хокукын, тигез хокуклылык, ireклелек һәм үз ихтыярыңны белдерү ирege принципларын тану нигезендә, унитар дәүләтне договор-конституцион федерациягә корылган федерациягә таба котылгысыз үзгәртеп кору юнәлешендә нык сизелерлек ыргылыш ясалды.

Конституциядә беренче тапкыр буларак ***хокукый дәүләт принциплары*** формалашты, дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеге шулар нигезендә гамәлгә ашырыла. Болар - законнарның өстенлеге, аларны тайпылышсыз үтәү, законнар эшләү, башкару һәм суд хакимиятләренең бүленеше. Гомумтанылган принципларның һәм халыкара хокук нормаларының Татарстан Республикасы законнарыннан өстенлеге игълан ителде.

***Беренче*** тапкыр буларак, Төп Законда ***шәхеснең*** Гомуми кеше хокуклары декларациясендә тәгъбир ителгән ***төп хокуклары һәм ирекләре*** закон нигезендә рәсмиләштерелде.

Татарстан Республикасы кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен тануны, саклау һәм яклауны, аны теләсә нинди законсыз тыкшынудан яки чикләүдән саклап калуны үз җаваплылыгына алды. Социаль-икътисадый хокуклар һәм ирекләр дә үзара җаваплылык принципларына нигезләнә. Болар: картлыкта, авырганда, хезмәткә яраклылыкны тулысынча яки өлешчә югалтканда, бала туганда һәм ул законда билгеләнгән яшькә җиткәндә матди тәэмин ителү хокукы; дәүләт уку йортларында түләүсез гомуми урта һәм махсус урта белем алу хокукы; сәламәтлекне саклауга хокук һ.б. Аларны үстерә бару максатында, республиканың законнар чыгару органы тулы бер законнар блогы кабул итте, һәм шушы юнәлештә без киләчәктә дә татарстанлыларның тормыш хәлен яхшырту өчен үзебезгә бәйле булганнарның бөтенесен эшләячәкбез.

Конституция хезмәткә хокукны һәм хезмәткә түләүне закон нигезендә билгеләнгән минималь эш хакыннан да түбәнрәк алмау хокукын беркетә. "Минималь эш хакы турында" Татарстан Законы нигезендә бездә эш хакын яшәү өчен минималь күләм дәрәҗәсендә тотарга мөмкин булды. Соңгы өч елда минималь эш хакы 110 сумнан 350 сумга яки 3,2 тапкыр күтәрелде.

Ләкин, Татарстанда минималь эш хакы тулаем Россиядәгедән шактый югарырак булуга карамастан, бүгенге хәл безне канәгатьләндерә алмый. Бу исә күп яктан шуның белән бәйле: финанс-икътисадый кризис нәтиҗәсендә яшәү минимумы дәрәҗәсенең күрсәткече шактый үсте, һәм ул инде без билгеләгән планканы узып китә. Шунлыктан биредә проблемалар бар, һәм без аны, һичшиксез, хәл итәрбез.

Хәзер, Россия Федерациясе төбәкләренең күпчелегендә социаль - икътисадый проблемалар кискенләшкәндә - 7 октябрьдәге протест акциясе масштаблары да моны ачык күрсәтте - безнең республикада реформалар китереп чыгарган кискен социаль киртәләрне үтү өчен чаралар күрелә. Россия икътисадының озакка сузылган авыруы - эш хакын түләүне күп айлар буена сузу (ә бу күренеш безнең республикада да күзәтелә), бәяләр арту һәм эшсезлек үсү кешеләрдә урынлы нәфрәт тудыра. Кешенең хезмәткә хокукы дәүләтне башкарылган эшкә үз вакытында түләү өчен икътисадый шартлар тудырырга мәҗбүр итә. Дәүләтнең дә, эш бирүчеләрнең дә мөһим бурычы бу. Социаль хезмәт өлкәсендә хәлнең динамикалы үзгәрә баруына оператив реакция ясау һәм социаль низагларны хәл итү өчен кирәкле хокукый база булдыру - бүген хакимият һәм идарә органнарының иң мөһим бурычларыннан берсе. Бу өлкәдә күрелә торган чараларның эзлеклелегенә һәм тирәнлегенә җәмгыятьнең үз-үзен ничек хис итүе нык бәйле: җәмгыять катлаулы реформалар юлын киләчәктә дә цивилизацияле үтәрме яки социаль киеренкелек артка тәгәрәүгә, тупикка китереп терәрме?

***Конституция*** нигезендә Татарстан ***үз гражданлыгына ия,*** бу - суверен дәүләтнең аерылгысыз билгесе. Конституциядә билгеләнгән бу норма Россия Федерациясе белән төзелгән Шартнамәдә тагын да үсеш алды, нәтиҗәдә бу мәсьәлә бары тик республика компетенциясендә генә тора. Гражданлык институты гражданның җәмгыять һәм дәүләт белән тотрыклы хокукый элемтәдә торуын күздә тота. Өстәвенә бу элемтә үзара хокукларда, бурычларда, җаваплылыкта гәүдәләнә һәм шәхеснең дәрәҗә-абруен, төп хокукларын һәм ирекләрен тануга һәм ихтирам итүгә нигезләнә.

Шушы вәкаләтне гамәлгә ашыра барып, Дәүләт Советы "Татарстан Республикасы гражданлыгы турында" закон проекты кабул итте. Соңгы чорда Россия җәмгыятенең үсеш диалектикасы, сәяси хокукларны тәэмин итү буенча объектив төстә үсә баручы таләпләр, үзебезнең хокукый кырыбызны булдыру һәм ныгыту уңаеннан, реформалар үткәрү, җиргә хосусый милек хокукын беркетү уңаеннан, республика гражданнары мәнфәгатьләренең өстенлеге һәм аларны яклау - менә болар барысы да әлеге законны тизрәк кабул итү кирәклеген нык таләп итә.

Үз гражданлыгыбызны тану белән беррәттән, республика Конституциясе Татарстан гражданнарына Россия Федерациясе гражданлыгын да беркетә. Россиянең яңа паспортларын кертү кеше хокукларының гарантиялелеге проблемасын, республика гражданлыгы институтын яклау механизмын, шулай ук милли телләр һәм мәнфәгатьләрне яклау механизмын тәэмин итү проблемасын бөтен яктан ачты. Россия Федерациясендәй күп милләтле дәүләттә гражданлык, тел һәм этник яктан тыгыз бәйләнеш яшәп килә. Шунлыктан бу факторлар белән исәпләшмәү милли республикаларда урынлы ризасызлык китереп чыгарды һәм Федерациянең күп субъектларында зур иҗтимагый-сәяси яңгыраш тудырды. Россия гражданлыгы мәсьәләләрен барлык якларның фикерен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып хәл итү максатка ярашлы. Безнең принципиаль позициябез менә шунда. Татарстан Республикасы Президенты һәм Дәүләт Советы бу хакта инде кат-кат белдерделәр.

Конституция халкыбыз өчен милләтара ышаныч һәм татулыкның үзенчәлекле катехизисына (кагыйдәләр-ред.), ***милли мәнфәгатьләрне һәм телләрне, гореф-гадәтләр һәм традицияләрне яңарту һәм үстерүнең*** универсаль законына әйләнде. Татар һәм рус телләрен дәүләт теле һәм тигез хокуклы тел сыйфатында беркетү бик тә мөһим сәяси -хокукый норма булды.

Татарстан гражданнарының тигез хокуклылыгы турында Конституциядә билгеләнгән нигезләмәләр нинди милләттән булуыңа, телеңә, дини инануыңа бәйле түгел. Туган телеңнән файдалану гарантиясе республика законнарында да үсеш алды. 1992 елда "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Закон кабул ителде, ул исә тел өлкәсендәге мәсьәләләрне җайга салуның хокукый нигезен тәшкил итә. Аны тирәнәйтү юнәлешендә Татарстан халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасы кабул ителде. Ул, аерым алганда, милли белем системасын киңәйтүне, Татарстанда яшәүче халыклар телендә әдәбият бастыруга булышлык итүне, бу өлкәдәге фәнни тикшеренүләрне финанслауны, массакүләм мәгълүмат чараларында тел төрлелегеннән файдалану өчен шартлар тудыруны күздә тота.

Соңгы елларда Татарстанда милли белем системасын үстерү өлкәсендә күп эшләнде һәм эшләнә. Белем бирүнең милли-региональ стандарты буенча Татарстан варианты булдырылды һәм ул бу сынауны уңышлы үтә. Аның нигезендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә һәм уку йортларында укыту-тәрбия процессын үзгәртү гамәлгә ашырыла, яңа белем институтлары булдырыла. Уку планнарына милли учреждениеләрне исәпкә ала торган яңа фәннәр: татар халкы тарихы, татар теле һәм әдәбияты, Россия халыклары тарихы һ.б. кертелде.

Шуны гына әйтү дә җитә, әгәр 1992 елда татар балаларының 28 проценты гына туган телендә укыса, 1998 елда исә 47 проценты диярлек укый. Чуаш, удмурт, мари, мордва балаларының милли белем алуына шактый зур игътибар бирелә; яһүд, әзербәйҗан, әрмән, украин һ.б. милләт балалары өчен якшәмбе мәктәпләре ачылды. Татарстанны үзләренең туган йорты дип санаган барлык милләт вәкилләренең мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алу дәүләт милли сәясәтен үткәрүнең югары өстенлеге булып тора.

***Дәүләт*** суверенитетын игълан итү һәм Конституцияне кабул итү Татарстанга реаль хокуклар һәм вәкаләтләр алырга, ***радикаль социаль - икътисадый реформалар үткәрүдә үз юлын сайларга*** мөмкинлек бирде. Кайчак безне акрын кыймылдауда гаепләделәр. Ләкин сәясәттә без беркайчан да нинди да булса абстракт фикер - карашлардан чыгып эш итмәдек, реформаларның, беренче чиратта, тормыш сыйфатының күтәрелүенә, социаль тотрыклылыкның тагын да ныгый баруына хезмәт итәргә тиешлегеннән чыгып эш иттек.

Федераль үзәк кайчак без керткән яңалыкларга каршы чыкты яки хәтта аларны тулысынча кире какты, ә тора - бара үзе дә аларны файдаланды һәм федерация субъектлары арасында алдынгы тәҗрибә буларак та таратты. Социаль юнәлешле базар идеясе белән чыккач та шулай булды; нәкъ менә кеше, аның ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре безнең өчен барлык үзгәртеп коруларның максаты булып тора бит, югыйсә. Гайдар реформаларының "шок терапиясе"ннән аермалы буларак, Россиядә стихияле базар хакимияте яңа икътисадый мөнәсәбәтләр булдыруның төп көйләгеченә әверелгән чорда, безнең республика җитәкчелеге дәүләтнең көйләүче ролен көчәйтү юлына басты, базар формалашуның беренче этапларында аның эчке сәбәпләр аркасында барлыкка килгән эшкә сәләтсез субъектлары өлгереп җитүнең мөмкин түгеллеген аңлап эш итте. Бу, аерым алганда, илебез товар җитештерүчесен яклауда да, алкоголь продукциясе җитештерүгә һәм аның әйләнешенә дәүләт монополиясен торгызуда, халыкны адреслы социаль яклау сәясәтен үткәрүдә, тузган торакны бетерү һәм торак пунктларга газ кертү программаларын гамәлгә ашыруда да чагылыш тапты. Болар барысы да бүген дә, милли валютаның, банк системасының һәлакәтле җимерелүе шартларында да, безнең өчен социаль - икътисадый сәясәттә өстенлекле юнәлеш булып тора.

Реформалар үткәрүгә федераль үзәк дәрәҗәсендә анализ ясау шуны күрсәтә: хәзер, кайчандагыга караганда да, вакытлы ыргылышлар гына түгел, ә ритмлы, салмак адымнар кирәк. Уңай үзгәрешләр эволюцион тәртиптә түгел, ә кирәкле төзәтмәләр белән, тетрәнүләрсез үтәргә тиеш. Күп илләр тәҗрибәсе шуны инандырырлык итеп күрсәтә: идарә итү, профессионализм, системалы үзгәрешләр тиешле югарылыкта булганда гына үзгәртеп коруларда да зуррак һәм сизелә торганрак уңышларга ирешеп була.

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев, Дәүләт Советы һәм хөкүмәт шуны тирәнтен аңлап эш итәләр: мөһим бурычны хәл итү-макро икътисадый тотрыклылыкны торгызу һәм базар реформаларын тирәнәйтү - бары тик дәүләт үз эшчәнлеген ныклы закон нигезендә корганда һәм барлык тармаклар, хакимият институтлары хокук һәм норма принципларын тайпылышсыз саклаганда гына мөмкин. Дәүләт ресурсларын өстенлекле, социаль - икътисадый юнәлешләргә туплау буенча мөһим адымнар ясау кирәк. Илебез товар җитештерүчесенә салымнар йөген киметү, реформалар чорында бюджет чыгымнарын аның керемнәре белән нык яраштыру мөһим. Федераль сәнгать сәясәтен гамәлгә ашыруда оборона тармагы предприятиеләренең функцияләрен ачык билгеләргә кирәк. Милек хокукын тәэмин итүгә һәм эшмәкәрлекне барлык чаралар белән үстерүгә муафыйк караш булса, болар эшсезлекне киметүнең һәм салым керемнәре арта баруның мөһим факторына әверелә барыр иде.

Республика Конституциясендә беркетеп куелганча, Татарстан Республикасы икътисадының нигезен ***иҗтимагый базар хуҗалыгы*** тәшкил итә, анда закон нигезендә хуҗалык эшчәнлеге ирege һәм милекнең күп төрлелеге тәэмин ителгән. Берничә ел элек үк инде без, Россия Федерациясендә беренчеләрдән булып, җитештерүнең төп средствосы буларак җиргә хосусый милекнең кагылгысызлыгын игълан иттек һәм аны юридик яктан рәсмиләштердек. Быел Дәүләт Советының яңа Җир кодексын, шулай ук тиешле законнарны кабул итүе җир реформаларына, шул исәптән нәтиҗәсез файдаланыла торган җирләрне базар әйләнешенә актив тартырга булышлык итәчәк. Бу бик мөһим. Чөнки азык-төлекне тотрыклы һәм гарантияле житештерү өчен шартлар булдыру һәм аның белән халыкны тәэмин итү социаль яклау системасының бик мөһим өлеше булып тора.

***Төп*** Законда ***"Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятен оештыру"*** дигән бүлекнең барлыкка килүе принципиаль яктан яңа нәрсә булып тора, аның төп нигезләмәләре республикада 90нчы елларда барлыкка килгән сәяси һәм социаль - икътисадый чынбарлыкны чагылдыра.

# ЭШЕ БАРНЫҢ АШЫ БАР

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*

Ягулык - майлау материаллары өчен кредит та алмаска дип уйлап торалар: кыйммәткә төшә. Киләсе елга 5000 гектарда бөртекле культуралар чәчәргә планнары. 1000 гектарда чөгендерне кулдан эшкәртеп үстерү кулай булыр дип саныйлар, моның өчен җирләре әзер, гербицидка кадәр бирелгән. "Французлар безне чөгендер үстерергә өйрәттеләр, хәзер без алар белемен үзебезнең җирлеккә яраклаштырып кулланырга ниятлибез",- дип аңлатты бу уйны Ильяс Нургалиевич.

Гомумән, агрофирма рәисенең һәр сүзендә хуҗаларча фикер йөртү, алга карап яшәү сизелә иде.

- Единениедә яшелчәчелекне торгызачакбыз. Көнбагыш игү белән шөгыльләнергә җыенабыз. Ул бик табышлы. Күпьеллык үләннәр үстерү белән җитди шөгыльләнер вакыт җитте. Быелдан донник, люцерна, козлятник орлыклары туплап куйдык... Начар яшәмәбез. Әмма моның өчен сезнең намуслы, аңлы хезмәтегез дә кирәк.

Шул арада көндәлек хезмәткә күчеп, әле алдагы көндә генә үткән техниканың торышын тикшерүгә тукталып алды: Каравыл Тавы механизаторларына тырышасы бар. Бер хуҗалыкта эшкә төрле караш булырга тиеш түгел, чөнки хезмәт начар бәяләнми бит.

Әйе, хуҗалык рәисенең таләпчән булырга хакы бар иде.Агрофирма - бүгенге шартларда да икътисадый тотрыклылыгын саклаган, үз колхозчыларына хезмәт хакын даими биреп баручы хуҗалыкларның берсе бит. Бәйрәм көнне механизаторлар хезмәтенә тулысынча түләнәчәк иде, ноябрь аенда тулаем хуҗалык эшчәннәре белән исәп - хисап ясарга ниятләрен әйттеләр. Бүгенге көнең мул, иртәгәге көнең ышанычлы булганда, ничек намуслы хезмәтеңне кызганырга кирәк?

Бәйрәм кунакларының чыгышлары да шул рухта иде. Район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В. Терентьев, хакимият башлыгының аппарат җитәкчесе Ф.Р.Ногъманова, шефлары - "Татнефть" - Нурлатнефтеразведка" АҖ җитәкчесе А.С.Насолдин агрофирмалыларга уңышлар теләделәр.

Бәйрәмдә катнашучылар әйбәт кәеф белән чәй табыннары артына таралыштылар, ә кич белән агрофирмалыларны унъйортлыкларда күңел ачу көтә иде.

Менә шул иде инде халык мәкаленең тормышта чагылышы: эше барның ашы бар!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**



*С.МАЙСТЕР фотосы.*

## *Дмитрий Второв:*

# «ТЕЛЕВИДЕНИЕ ЧИРЕ ЙОКТЫ МИҢА»

***Татарстан телерадиокомпаниясенең рус телендәге "Яңалыклар" программасын алып баручы Дмитрий Второвка бары егерме ике яшь, әмма аның шул гомерен дә ике кисәккә бүлеп карарга мөмкин инде. Телевидениегә кадәрге һәм телевидение чорларына. Шунысы бар, ул чорларның икенчесе беренчесеннән әллә ни кыска түгел. Алты яшьлек чагында әтисе телестудиядә эшләүче таныш яктыртучысы янына алып килә аны һәм Дмитрий озакламый телевидение чирен "йоктыра". Аның катыргы тартмалардан телевизорга охшаш нәрсә әвәләп, шуннан башын тыгып сөйләп каравыннан олылар көлсә дә, үзенең хыялыннан кайтырга ашыкмый ул. Сигезенче класска күчкән Дмитрий 1991 елның августы вакыйгалары барганда телевизор каршыннан аерылмыйча утыра, ә инде бер айдан Казанның Ленин районы яшьләр торак комплексы студиясеннән беренче тапшыруын алып бара. Атнага өч тапкыр мәктәп балалары өчен яңалыклар алып бара ул, озакламый аны йөзгә таный башлыйлар, студиягә шалтыратып үзенә яңа идеяләр тәкъдим итәләр. Аннан "Эфир" каналы. Ә бераздан Дмитрий... Үзәк телевидение өчен сюжетлар әзерли башлый. Хәтерегездәме, "Саескан" һәм "Там - там новости" дигән тапшырулар бар иде? Ә бер бик уңышлы чыккан сюжетын иртәнге "Чулпан" программасында да кабатлап күрсәткәннән соң, аны Татарстан телевидениесе белән хезмәттәшлек итәргә чакыралар. Аннан соң дүрт ел вакыт үтеп киткән инде. Дмитрий Второв "Чулпан", "Иртәгә" программаларында катнаша, ә 1996 елның апреленнән "Яңалыклар"да эшли. Быел Нурлатта гына да ике тапкыр булды. Бик ачык күңелле кеше икән, сорауларга җавап бирүдән качарга тырышмый...***




***- Дмитрий, эшегезнең, хәтта әле уңышыгызның да төп элементлары нидә дип саныйсыз?***

- Бирелә торган мәгълүматны ничек тә тирәнрәк эчтәлектә җиткерү - безнең коллектив өчен менә шунысы мөһим. Монда күп нәрсә һөнәрмәннәрнең аңлатмаларын алуга ирешүгә бәйле.

***- Сезнең өчен эфирның "алтын" кагыйдәсе бармы?***

- Кыскача гына әйтсәк, объективлык һәм оперативлык ул.

***- Сезнең телевизион көнегез ничек уза?***

- Аңладым соравыгызны. Димәк... Студиягә иртәнге сигезләрдә киләм. Материал өстендә эшлим. Көндезге сәгать бердә безнең "Яңалыклар" студиясендә элеккеге көнге тапшыруларны энәсеннән җебенә кадәр тикшерү була - уңай һәм җитешсез яклар да, тамашачылар фикере дә телгә алына. Шунда ук коллективта (ә бездә 20 кеше) кичке чыгарылышларның программасы аныклана, иртәгәге көнгә төшкә кадәрге бурычлар да билгеләнә. Вак -төяк эшләр бик күп: вакыйга урыннарына бару, төшерү, яздыру, телефоннан сөйләшүләр... Кичке сәгать дүртләр - бишләрдә тапшыруны монтажлау башлана. Программаны үзең алып барган көнне өйгә төнге берләрдә кайтып керәсең.

***- Үз тормышыңа вакыт та калмый түгелме соң? Ә гаилә?***

- Шәхси тормыш дигәнне мин гаилә мөнәсәбәтләре белән генә чикләмим, ә дуслар, хезмәттәшләр белән аралашуны да шунда кертәм. Шунсыз нинди тормыш ди инде ул. Телевидение бер шөгыль генә түгел, яшәү образы да бит ул. Бары шуның кагыйдәсенә буйсынып яши башлыйсың һәм ул сиңа графикны үзе төзеп бирә. Шуңа күрә күп нәрсәләрдән баш тартырга да туры килә.

***- Алып баручының имиджы турында кемнәр кайгырта?***

- Бездә гример һәм стилист бар, без аларның тәкъдим - киңәшләренә колак салабыз.

***- Заманнан артта калмас өчен ниләр кыласыз? Күп укыйсызмы, коллегаларыгызның тәҗрибәсенә игътибар итәсезме?***

- Бик теләсәм дә, китаплар укырга вакыт тими диярлек. Ышанасызмы, кайчагында ОРТ яңалыкларын карап барырга да мөмкинлегем булмый минем. Есенинны бик яратам мин, Лев Толстойны һәм Достоевскийны нығытып укып чыгасы килә... Тик, кызганычка каршы, әлегә вакыт кытлыгы үзенеке итә.

***- ТДТРКга Илшат Әминев килгәннән соң нәрсәләр үзгәрде?***

- Җитәкчелек һәм коллектив арасында әкренләп үзара аңлашу урнаша башлады.

***- Дәүләт телевидениесендә кертелә торган яңалыкларга карата сезнең фикерегез нинди?***

- Тапшыруларның яңа челтәре әле эксперимент рәвешендә генә һәм 1999 елның 1 гыйнварена кадәр барачак. Әлегә рейтинг нәтиҗәләре юк, әмма "Яңалыклар"ның икенче чыгарылышы төнге унбер тулганда булу аркасында,сүз дә юк, тамашачыларыбызның бер өлешен югалттык без. Дөрес, чыгарылышның вакыты 5 минутка озайтылды. Тапшыруларның вакытын үзгәртүнең максатлары изге анысы: татар һәм рус телендәге тапшыруларны бертигезрәк шартларга кую һәм, шулай итеп, оешканлыкка ирешү. Дөрес, бу уңайдан фикерләр төрле әле һәм алар өйрәнелә хәзер.

***- Дмитрий, үзегезне тагын нинди дә булса тапшыруларда сынап карар теләгегез юкмы?***

- Ул сорауны еш бирәләр миңа. "Яңалыклар"да эшләү барышында мин үземне күп яклап сыныйм бит инде һәм шуңа да нинди дә булса яңа программа төзү теләгем юк.

***Әңгәмәбез шуның белән төгәлләнде. Дмитрий Второвны яңа маршрутлар көтә иде.***

***Т.НАЗАРОВА.***
***Н.АЗИЗОВ фотосы.***

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Кадерле **әниебез, әбиебез Факия Нәҗип кызы Мирзаҗанованы** 70 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.

"Әни" диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз, һич ярамый
"Әни" сүзен таптарга.

**Иң изге теләкләр белән улллары, кызлары, килennәре, кияүләре, оныклары исемннән Ландыш.**

Югары Нурлат авылында яшәүче **кадерле әтиебез Нурулла Хөснулла улы Нотфуллинны** 70 яше белән кайнар котлыйбыз. **Әниебез Сәрбиназ** белән бергә гомер итүләренә 50 ел тула. Исәнлек - саулык, бәхет теләп

**Ранас, Люция, оныгыгыз Альбина.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Җир участогы.** Тел.: 2-12-53.

***

**1987 елгы ВАЗ - 2108.**
Тел.: 5-11-62, эш көннәрендә кичке 6дан соң.

***

**Табигый газ һәм каты ягулык белән эшли торган җылыткыч аппарат.** Тел.: 5-13-78.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Яшьләр үзәгендә 14 ноябрь көнне иртәнге 9дан көндезге 2гә кадәр Ульян күн фабрикасы натураль тиредән эшләнгән көзге - кышкы аяк киемнәре сата.**

***

**ВАЗ - 2107 автомобиленә документлар табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз.** Тел.: 5-23-97.

***

**Ринат Абдуллин исеменә шофер таныклыгын табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйм.** Адрес: Совет ур., 143 - 11.

***

**Олег Леонтьевич Семенов исеменә документлар табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйм.** Адрес: К.Маркс проспекты, 9 - 32.

***

**Октябрь МСОсының 1нче ПМКсына даими эшкә электрик кирәк.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4340